**Аннотация к рабочей программе воспитателей по обучению родному языку МБДОУ «Костенеевский детский сад» ЕМР РТ**
**Широбокова Н.Ф.**

"Татарстан Республикасы халыклары телләре турында" Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә мили белеем бир үөчен кирәкле шартлар булдыру каралган.

"Балалар бакчасында рус һәм башка милләт балаларын татарча аралашырга һәм татар балаларын ана теленә өйрәтү" программасы (алга таба программа) алда күрсәтелгән чыганакларга нигезләнеп төзелде.

Программа 2 яшьтән 7 яшькә кадәр булган татар балаларын ана теле, 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларның татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләрен үз эченә ала. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына, сөйләм барлыкка килү концепциясенә (Л. С. Выготский, В. В. Давыдов, Е. И. Пассов, П. Я. Гальперин),гамәлиэшкәртмәләрһәмметодиккиңәшләргә,мәктәпкәчәмәгарифсистемасы эшчәнлегеначыклаучынормативхокукыйактлар,нигезләмәләренәкөйләнгән.

**Программаның максаты һәм бурычлары.**

"Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү" программасына нигезләнеп "Татарча сөйләшәбез" укыту-методик комплекты 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларны 167 сүз кысаларында татарча аралашырга өйрзтүне үз эченә ала. Шуннан чыгып эш программасына түбәндәге максат, бурычлар билгеләнде.

Максат: Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны 167 сүз кысасында информацион–коммуникатив технологияләр кулланып татарча аралашырга өйрәтү.

Бурычлар:

1.Сүз байлыгын арттыру, сөйләм күнекмәләре формалаштыру.

2.Предметларны, аларның билгеләрен һәм хәрәкәтне белдерүче сүзләрне сөйләмдәактивлаштыру.

3.Көндәлек яшәеш ситуацияләреннән чыгып диалоглар төзү.

"Туган телдә сөйләшәбез" укыту-методик комплекты балалар бакчасында беренче кечеяшьтәге,икенчекечеяшьтәгеләр,уртанчылар,зурлар,мәктәпкәәзерлектөркемнәрендә татар балалары белән эшләү өчен тәкъдим ителә. Шуннан чыгып татар төркемнәрендә тәрбияләнүче балаларга ана телен өйрәтү өчен эш программасына түбәндәге максат, бурычларбилгеләнде.

Максат: Балаларны информацион–коммуникатив технологияләр кулланып ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү.

Бурычлар: 1.Тел системасының фонетик, лексик, грамматик

төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру.

2. Бәйләнешлесөйләмнемөстәкыйльфикерйөртүнәтиҗәсебуларакүстерү.
3. Телһәмсөйләмкүренешләренаңлау(тоемлау)сәләтебулдыру.